# ИМАМ ИБН ‘АСАКИР РИСӘЛӘСЕ

Бөек Имам Фахруд-Дин Ибн ‘Асакир (аңа Аллаһ Тәгаләнең рәхмәте булсын!) әйтте:

«Бел ки: Аллаһ Тәгалә сине дә, безне дә тугъры юлга күндерсен[1] – һәрбер мүкәлләф[2] белергә тиешле булган мәгълүмәтьләрдән шул: Аллаһ Тәгалә – бердән бер Хөкем итүче. Ул бөтен галәмне яралтты – өске галәмне дә, аскы галәмне дә, Әль-‘Арш һәм Әль-Күрсийне, күкләрне һәм җирләрне, вә алар арасында булган бөтен нәрсәләрне яралтты. Бөтен барлык – Аллаһ Тәгаләнең Кодрәте астында. Аллаһ Тәгаләнең Ирадәсеннән башка з̲әррә[3] дә кыймылдамас.

Яралтуда Аңа һичбер уртак[4] юк. Вә Хөкем итүдә дә бер нинди уртак юк.

Аллаһ Тәгалә Тередер. Ул бер кемгә дә мохтаҗ түгел. Ару, талу вә йокы кебек нәрсәләр Аңа әйтелмәс[5].

Ул бөтен нәрсәне белүчедер, вә күкләрдә һәм җирләрдә булган бер ни дә Аңардан сакланып калмас[6]. Аллаһ Тәгалә коры җирдә вә суда булган һәр нәрсәне белүче. Һәрбер төшә торган яфракны да белә, вә җирдә яткан һәрбер орлыкны да белә, вә бөтен юеш һәм коры нәрсәләр турында белә. Ул һәрбер зат турында белә, вә бөтен нәрсәнең санын белә.

Аллаһ Тәгалә ни теләсә – эшли, Аның Кодрәте бөтен нәрсәгә җитә. Аңарда Хөкем[7]. Ул Үзе Үзеннән бар[8], Ул бер кемгә дә мохтаҗ түгел.

Аллаһ Тәгаләгә мактаулар булсын! Ул бөтен нәрсәнең Хуҗасы[9], Ул мәңге бар булучы, Аның ахыры юк. Ул Хөкем итә, Ул юктан бар итә[10].

Аның иң күркәм Сыйфатлары[11] бар. Аллаһ Тәгаләнең яралтуында һичбер киртә юк. Вә Ул биргәненә каршы чыгучы юк. Ул Үзенең мөлке белән теләгән нәрсә эшли, вә Ул Үзенең яралтканнарына Үзе теләгәнчә хөкем итә.

Аллаһ Тәгалә сәвап сорамый вә газәптән курыкмый[12]. Ул бер кемгә дә бер ни дә тиеш түгел. Вә бер кем дә Аны хөкемгә тартмас.

Һәрбер нигъмәт – Аллаһ Тәгаләнең рәхмәтеннән вә һәрбер газәп[13] – Аның Гаделлегеннән[14]. Аллаһ Тәгаләне сорамаслар: «ни өчен шулай эшләдең?» – дия. Әмма мәхлүкатьләр соралачаклар. Аллаһ Тәгалә мәхлүкатьләрне яралтканчы Үзе бар иде.

Аллаһ Тәгаләгә шушындый сыйфатлар лаек түгел: әүвәл, ахыр, астында, өстендә, уңында, сулында, алдында, артында. Һәм дә Аллаһ Тәгаләгә шулай да әйтелмәс: бөтенләй я дә өлешле, әгъзалы, ни вакыт Ул булды, кайда булды, нинди Ул.

Аллаһ Тәгалә мәңге әүвәлсез булган әмма урын[15] булмаган иде. Ул галәмне яралтты вә вакытны яралтты.

Ул Үзе вакытка да багълы түгел, урынга да багълы түгел. Аллаһ Тәгалә теләгәненә берни дә һәм беркем дә каршы килә алмас[16].

Безнең төшенечләр белән Аллаһны аңлап булмый[17]. Аның Затына акыл ирешерлек түгел вә чолгап алуның мөмкинчелеге юк. Аллаһ Тәгаләне фикер белән берәр кыяфәттә төшерү мөмкин түгел. Шулай ук Аны фикрдә бер нинди рәвештә дә төшерү мөмкин түгел. Аллаһны бер ничек тә күз алдына китерү мөмкин түгел.

Аллаһ Тәгаләгә бер нәрсә дә охшамас, Ул һәр нәрсәне Ишетүче[18] вә Күрүче[19]».

---

[1] Тугъры юлда сакласын, адаштырмасын.

[2] Мүкәлләф – Ислам Динебез турында ишеткδн балигъ булган гакыл иясе.

[3] З̱әррә – иң кечкенә булган нәрсә. Аллаһ Тәгалә бөтен нәрсәне яралтты вә Ул теләгәненнән башка бир ни дә булмас, кузгалмас, юк булмас: иң вак нәрсә з̱әррәдән башлап, иң зур нәрсә – Әль-‘Аршка хәтле – барчасы монда керә.

[4] Шәрик – уртак. Аллаһ Тәгаләгә һичбер шәрик юк: ни яралтуда, ни Сыйфатларында, ни мәңгелек Хәятендә, ни Бердән Бер булганында.

[5] Кушылмас, диелмәс, лаек түгел.

[6] Яшеренелмәс.

[7] Бөтен нәрсәләр Аллаһ Тәгаләнең мөлке вә Ул Үзенең мөлке белән теләгәнен эшли.

[8] Аны бер кем дә яралтмады, Ул әүвәлсез.

[9] Барысы да Аныкы, Ул барысын да яралтты – юктан бар итте.

[10] Юктан бар итү – яралту мәгънәсендә, Аллаһ Тәгаләдән башка юктан бар итүче юк.

[11] Аллаһ Тәгаләнең Сыйфатлары бөтен кимчелекләрдән пакь.

[12] Газәпне Ул Үзе бирүче, әмма Аңа карата газәп юк.

[13] Газәп – Җәза.

[14] Аллаһ Тәгалә бер кемгә дә золымлык итмәс, Аллаһ Тәгалә Гаделдер – Үзенең мөлке белән теләгән нәрсә эшләр. Әмма мәхлүкатьләр турында: гаделсезлек – башка бер хуҗаның рөхсәтсез вә ризасыз малын куллану. Аллаһ залим түгел.

[15] Урын – галәмнәр, күкләр вә җирләр һәм башка мәхлүкатьләрнең урыны.Өстә – урын, аста – урын, уңда – урын, сулда – урын, алда – урын, артта – урын, һәм бөтен җирләр – урын, әмма Аллаһ Тәгалә урынсыздыр.

[16] Уңайсызлау, комчаулау да китерә алмас.

[17] Чөнки безнең төшенечләр – яралтылган, әмма яралтылган Яралтучыны аңламас вә төшенә алмас.

[18] Ишетүе исә колак белән түгел, Аллаһ Тәгалә һәр нәрсәне ишетә, әмма безнең кебек түгел, Аның әгъзалары юк.

[19] Күрүе исә күз белән түгел, Аллаһ Тәгалә һәр нәрсәне күрә вә күрүе дә нур белән түгел, Ул безгә охшамас, бер нәрсәгә дә мохтаҗ түгел.

**Бу брошюраны пычырак җирләргә куерга ярамый.**
**Диний кәгазьләрне хөрмәтләргә кирәк.**

**Эту брошюру нельзя класть в грязные места и неуважительно относится к ней. Ее нужно сохранить.**